**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» 06 2022 ел Яр Чаллы шәһәре №1753

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә урнашкан 16:39:100101:218, 16:39:100101:219 кадастр номерлы җир кишәрлекләрененең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, Тукай муниципаль районы уставы, 2022 елның 19 маендагы халык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ

1. Шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртергә:

- Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә урнашкан 16:39:100101:218 кадастр номерлы җир кишәрлегенең «Гомуми мәйданы 150 кв. метрдан артмаган беренче чиратта кирәкле товарлар кибетләре» төп төрен «Магазиннар» шартлы-рөхсәт ителгән төргә;
- Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегендә урнашкан 16:39:100101:219 кадастр номерлы җир кишәрлегенең «Шәхси торак йортлар. Гомуми мәйданы 150 кв. метрдан артмаган беренче чиратта кирәкле товарлар кибетләре» төп төрен «Магазиннар» шартлы-рөхсәт ителгән төргә.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин